АГЕНТСТВО
ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ
АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**«15» февраля 2016г.** № 13/2лс

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендәге затларның чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Президентының 2016 ел 12 гыйнварындагы ПУ-5 номерлы «Аларга билгеләп кую һәм азат итү  Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган  Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен кабул итүе тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»гы Указының 3нче пунктына, Россия Федерациясе Президентының 2015 ел 10 октябрендәге 506 номерлы «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, аерым федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерымлык билгеләрен кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы Указына, 2004 ел 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында»гы Федераль Законга туры китереп боерам:

1. Түбәндә беркетелгән Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендәге затларның чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм

махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Т.И.Минуллина

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгының
__________ №_____________

Боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендәге затларның чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтен башкаручы затларның (алга таба – гражданлык хезмәтендәге зат, Агентлык), вазыйфа бурычларына әлеге оешмалар һәм берләшмәләр белән бәйләнештә тору кергән очракта, чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен (фәнни дәрәҗәләрдән тыш), бүләкләрен (алга таба – исемнәр, бүләкләр) кабул итү тәртибе билгеләнә.

2. Гражданлык хезмәтендәге зат мактаулы исемнәр, бүләкләр алганда Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы Җитәкчесенең (алга таба – Җитәкче) рөхсәтен алырга тиеш.

3. Мактаулы исем, бүләк алган яисә мактаулы исем, бүләк алачагы турында чит дәүләт, халыкара оешма, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә, дини оешмадан хәбәрнамә алган гражданлык хезмәтендәге зат өч эш көне дәвамында юридик бүлеккә Җитәкче исеменә чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы исемен яки махсус дәрәҗәсен, бүләген кабул итеп алырга рәхсәт бирүен сорап, 1нче Кушымтадагы форма нигезендә тутырылган үтенеч язуы (алга таба - үтенеч язуы) тапшыра. Үтенеч язуы 20 эш көне дәвамында карала.

4. Мактаулы исемнән, бүләктән баш тарткан гражданлык хезмәтендәге зат өч эш көне дәвамында Агентлыкның юридик бүлегенә Җитәкче исеменә чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы исемен яки махсус дәрәҗәсен, бүләген кабул итүдән баш тартуы турында әлеге Нигезләмәнең 2нче Кушымтасындагы форма нигезендә тутырылган хәбәрнамә (алга таба - хәбәрнамә) тапшыра.

5. Җитәкче тарафыннан үтенеч язуы каралып, нәтиҗә карары кабул ителгәнче мактаулы исем, бүләк алган гражданлык хезмәтендәге зат мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа караган документларның төп нөсхәләрен, аларны кабул итеп алганнан соң өч эш көне дәвамында Агентлыкның аларны саклау өчен җаваплылык йөкләнгән

юридик бүлегенә тапшыра. Бу уңайдан әлеге Нигезләмәнең 3нче Кушымтасы нигезендә кабул итү-тапшыру акты төзелә.

6. Гражданлык хезмәтендәге зат хезмәт командировкасы вакытында мактаулы исем, бүләк алган яисә алардан баш тарткан очракта, үтенеч язуы яки хәбәрнамә тапшыру вакыты гражданлык хезмәтендәге затның хезмәт командировкасыннан кайткан көненнән алып санала.

7. Гражданлык хезмәтендәге зат, үзеннән тормаган сәбәпләргә бәйле рәвештә, үтенеч язуын яисә хәбәрнамәне, мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа караган документларның төп нөсхәләрен әлеге нигезләмәнең 3-5 пунктларында күрсәтелгән вакытта тапшыра алмый икән, үтенеч язуын яисә хәбәрнамәне, мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа караган документларның төп нөсхәләрен әлеге сәбәпләр бетерелгәннән соң килгән эш көненнән дә соңга калмый тапшырырга тиеш.

8. Үтенеч язуы (хәбәрнамә), ул тапшырылган көнне әлеге Нигезләмәнең 4нче Кушымтасындагы форма нигезендә төзелгән теркәү журналына юридик бүлек тарафыннан кертелә. Теркәлгән үтенеч язуын (хәбәрнамәне) юридик бүлек өч эш көне дәвамында Җитәкчегә карар чыгару өчен тапшыра.

9. Юридик бүлек өч эш көне дәвамында гражданлык хезмәтендәге затка үтенеч язуын (хәбәрнамәне) карау нәтиҗәсендә кабул ителгән Җитәкче карарын хәбәр итә һәм Җитәкче карары күрсәтелгән үтенеч язуының (хәбәрнамәнең) мөһер белән расланган күчермәсен кул куйдырып тапшыра. Җитәкче карары күрсәтелгән үтенеч язуының (хәбәрнамәнең) төп нөсхәсе гражданлык хезмәтендәге затның шәхси эшенә беркетелә.

10. Җитәкче гражданлык хезмәтендәге затның әлеге Нигезләмәнең 5нче пунктында күрсәтелгән үтенеч язуын канәгатьләндергән очракта, Агентлыкның юридик бүлеге 10 эш көне дәвамында әлеге гражданлык хезмәтендәге затка мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа караган документларның төп нөсхәләрен тапшыра. Бу уңайдан әлеге Нигезләмәнең 3нче Кушымтасы нигезендә кабул итү-тапшыру акты төзелә.

11. Җитәкче гражданлык хезмәтендәге затның әлеге Нигезләмәнең 5нче пунктында күрсәтелгән үтенеч язуын канәгатьләндерүдән баш тарткан очракта, Агентлыкның юридик бүлеге 10 эш көне дәвамында мактаулы исем документларының төп нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа караган документларның төп нөсхәләрен чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини оешманың тиешле органына юллый.

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендәге затларның чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмәгә
1нче Кушымта

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесенә

____________________________________

____________________________________

(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфа)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини оешманың мактаулы исемен яисә махсус дәрәҗәсен, бүләген кабул итәргә рөхсәт турындагы үтенеч язуы

________________________________________________________________________

(мактаулы исем яисә махсус дәрәҗә, бүләкнең атамасы)

________________________________________________________________________

(нинди хезмәтләре өчен кем тарафыннан бирелгән, нинди хезмәтләре өчен кем тарафыннан бүләкләнгән)

________________________________________________________________________

(мактаулы исем яисә махсус дәрәҗәгә документлар, бүләк һәм аңа караган документларны тапшыру вакыты һәм урыны)

____кабул итеп алырга рөхсәт итүегезне үтенәм.

Мактаулы исемнең яисә махсус дәрәҗәнең документлары, бүләк һәм аңа караган документлар (тиешлесенең астына сызарга)

________________________________________________________________________

(мактаулы исем яисә махсус дәрәҗә, бүләкнең атамасы)

________________________________________________________________________

(мактаулы исем яисә махсус дәрәҗә, бүләкнең документлары атамасы)

_______ номерлы тапшыру-кабул итү акты буенча 20__ елның «__»_______ Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының юридик бүлегенә тапшырылды.

20__ елның «__»__________ ___________ _____________________

(имза) (имзаны шәрехләү)

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендәге затларның чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмәгә
2нче Кушымта

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесенә

___________________________________

___________________________________

(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфа)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, башка иҗтимагый берләшмәнең, дини берләшмәнең мактаулы исемен яки махсус дәрәҗәсен, бүләген кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә

___________________________________________________________________

(мактаулы исем яисә махсус дәрәҗә, бүләкнең атамасы)

___________________________________________________________________

(нинди хезмәтләре өчен кем тарафыннан бирелгән, нинди хезмәтләре өчен кем тарафыннан бүләкләнгән)

______кабул итүдән баш тартырга карар кылуым турында хәбәр итәм.

20__ елның «__»__________ ___________ _____________________

(имза) (имзаны шәрехләү)

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендәге затларның чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмәгә
Знче Кушымта

Кабул итү-тапшыру
акты

20__елның «__»_____ №____________

Без, түбәндә кул куючылар
________________________________________________________________ның
(Ф.И.А.и., вазыйфасы)
түбәндәгеләрне тапшыруы/кабул итүе,
(тиешлесенең астына сызарга)
һәм Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының юридик бүлеге____________________________________________________йөзендә
(Ф.И.А.и., вазыйфасы)
тапшыруы/кабул итүе турында акт төзедек.
(тиешлесенең астына сызарга)

| № | Атамасы | Саны (данә) | Тасвирламасы |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Тапшырды Кабул итте

________ ________________ ________ ________________
(имза) (имзаны шәрехләү) (имза) (имзаны шәрехләү)

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендәге затларның чит дәүләтләр, халыкара оешмалар, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмаларның мактаулы исемнәрен һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмәгә
4нче Кушымта

Үтенеч язуларын (хәбәрнамәләрне) теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № | Үтенеч язуын (хәбәрнамәсен) тапшыручы гражданлык хезмәтендәге затның Ф.И.А.и. | Үтенеч язуын (хәбәрнамәсен) тапшыручы гражданлык хезмәтендәге затның билгән вазыйфасы | Үтенеч язуының (хәбәрнамәнең) тапшырылу датасы | Бүләкнең, мактаулы исемнең атамасы | Кабул итү-тапшыру актының реквизитлары (булган очракта) | Үтенеч язуын (хәбәрнамәне) кабул итеп алган затның Ф.И.А.и, имзасы | Үтенеч язуын (хәбәрнамәне) бүлеккә тапшырган затның Ф.И.А.и, имзасы | Җитәкче карары турында мәгълүмат. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |